ЧИТАЕМ НА ТАТАРСКОМ

# Американ (Американец) — Кәрим Тинчурин

әле генә




Иллюстративное фото

**Сегодня в рубрике "Читаем на татарском" предлагаем вам прослушать пьесу классика татарской драматургии Карима Тинчурина – "Американ". Пьеса была написана в 1923 году, в том же году по этой пьесе был поставлен спектакль в Казани. Главную роль сыграл сам Тинчурин.**

Это сатирическая пьеса о жажде богатства, успеха и высмеивающая лицемерие, погоню за модой на всё "иностранное". За смешными ситуациями и яркими героями интересно наблюдать и читать, и слушать эту историю.

Текст пьесы сокращен и адаптирован для изучающих татарский язык.



Америкаи ... УРНАШТЫРУ КОДЫ УРТАКЛАШ
by Азатлык ...
0:00 35:10
аудио уйнаткыч
йөкләү

## Беренче күренеш

1920нче еллар башы. Хакимияткә большевиклар килгәч, Казанда белем алган студентларның да тормышы үзгәрә. Яшьләр яңа җәмгыять төзергә тырыша, ә иске тормыш тарафдарлары белән алар арасында каршылыклар бар.

Яңа фикерле студентларның берсе – **Искәндәр**. Ул зирәк, тапкыр һәм хәйлә корырга ярата. Аның дусты **Апуш** – шаян һәм җырларга яратучы егет. **Самат** исә җитдирәк: ул сак булырга, шикле эшләргә катнашмаска тырыша. Өчесе дә тарих түгәрәгендә катнаша. Аларның максаты – татар тарихына бәйле борынгы документлар һәм кулъязмалар табу, аларны өйрәнү.

Бүлмәгә Искәндәр белән Самат кайтып керә. Дуслары алардан мөһим яңалык көтә. Студентлар тарих түгәрәге өчен кирәкле материаллар эзләгәннәр, ләкин эшләре уңышсыз тәмамланган. Тарих түгәрәгенең киләчәгенә ышанмый бер дуслары. Аның фикеренчә, кирәкле материаллар табылмагач, түгәрәкне таратырга туры киләчәк.

Искәндәр исә моның белән килешми. Ул, киресенчә, "юкны бар итә белергә кирәк" дип саный. Бераздан студентлар янына **Зәйнәп** белән **Нурия** килеп керә. Алар да тарих түгәрәгендә катнашучы татар кызлары. Кызлар студентларга мөһим хәбәр алып килгән: шәһәрдә **Габдуллаҗан** исемле бай спекулянтта бик кыйммәтле тарихи материаллар саклана икән.

Габдуллаҗан элекке байлардан. Аңа тарих галим буларак кызык түгел, тарих аның өчен акча эшләү мөмкинлеге. Аның кулында Идел һәм Чулман буенда яшәгән борынгы халыклар тарихына бәйле документлар бар икән, менә шуны ачыклагыннарын җиткерә татар кызлары. Алар арасында борынгы кулъязмалар, Арслан хан заманыннан калган ярлыклар һәм ике йөз елдан артык элек язылган "Шаһнамә" кулъязмасы да булырга мөмкин икән.

— Тәгаен беләсеңме, Нурия? — дип сорады Искәндәр.

— Тәгаен беләм!

— Ә ничек, каян беләсең? — дип төпчендe башка егетләр.

— Әйтсәм әйтим инде, Габдуллаҗан асравы – минем апамның дусты. Шуның аркылы белдем. Аларда ул бар! Безгә кирәкле документлар Габдуллаҗан байда!

Кызлар бер-берсен бүлдерә-бүлдерә ни өчен ул документларны күрмәгәннәрен бәйнә-бәйнә аңлата башлыйлар. Габдуллаҗан тарихи ядкәрьләрне студентларга күрсәтергә дә теләми. Нурия үзе дә аның янына барып караган, ләкин бай аны кабул итмәгән. Студент икәнен белгәч, хәтта өеннән куып чыгарган.

Шуңа күрә хәзер тарих түгәрәге алдында яңа бурыч тора: Габдулҗанның кулындагы тарихи байлыкны ничек итеп кулга төшерергә?

Студентлар төрлечә уйлый. Самат бу эштән берни чыкмас дип саный, шунда ук бирешә, "Барып чыкмый бу эш, маташасы да түгел", дип әйтеп сала. Апуш исә материалларны милиция ярдәмендә алырга тәкъдим итә, ләкин бу да мөмкин түгел. Искәндәр исә башка юл эзли.

— Карагыз әле, дуслар, болар кем? Болар – мещаннар, ә аларның һәрберсе тотен җибәрергә, мактанырга ярата. Аларның ул ахмаклыкларыннан да, бәлки, берәр эш чыгып куяр, ә? Ничек уйлыйсыз? Моның өчен безгә аларның янына берәр модный, дәрәҗәле кешене ясап җибәрергә кирәк, — ди Искәндәр.

— Ни сөйлисең син? — дип ачуы килеп әйтә Самат.

— Сабыр, сабыр, иптәшләр. Ул документлар белән кызыксынып спекулянт Габдуллаҗанга килгән кеше зур кеше һәм хак мөселман булырга тиеш, икенчедән, каяндыр бик еpaктан килгән булырга тиеш. Өченчедән, аның ниндидер бер дәрәҗәсе булырга тиеш. Уйлап карагыз әле, үз арасында булмаганны борынгы халык күктән көткән. Ә хәзерге бездәге мещаннар заграницадан көтәләр. Әнә Габдуллаҗан бай да тарихи материалларны заграница өчен саклый дип уйлыйм, сатып күбрәк акча эшләргә тели ул, – ди Искәндәр һәм башына килгән хәйләне сөйләп бирә.

— Эврика! — дип кычкырып җибәрә ул. Искәндәр шатлыктан нишләргә дә белми. Ул, ниһаять, Габдуллаҗанның тарихи материалларын акчасыз алу юлын таптым дия.

Искәндәр барысына да карый да, бер сүз әйтә:

— Американ! Спекулянт Габдуллаҗанга американ киләчәк!

Искәндәр үзен Америкадан килгән зур дәрәҗәле татар итеп күрсәтергә тиеш булачак, ул байлар белән очрашып танышачак дип килешәләр.

## Икенче күренеш

Вакыйгалар **Муса** өендә дәвам итә. Муса – элеккеге җәмәгать хадиме. Аның кызы **Дилбәр** бар. Болар уртача бай яшәүче гаилә. Алар кунаклар көтә. Муса өйдәгеләргә кунакларны каршы алыр өчен пәрәмәчләрне яхшылап әзерләргә куша.

— Анасы, анасы, пәрәмәчне карап пешерегез. Итен, маен кызганмагыз. Кунак ни җитте кеше түгел, Америка профессоры! Ишетегез мине, бар нәрсә дә пөхтә булсын, — дип кычкыра ул өйдәгеләренә һәм үз мыегы астына сөйләвен дәвам иттерә. — Кара әле, бу профессор Америкадан нинди максат белән килде икән? Хөкүмәт эшләре беләнме икән әллә? Юк, юк, тәгаен өйләнергә килгәндер. Америка никадәр шәп булса да, тәрбияле милли кызлар юк шул анда. Бу инде үзе татар булгач, татар кызына, ягъни милли туташка өйләнүне тиеш тапкандыр, күрәсең. Туп-туры миңа килүе мәсьәләне тагын да мөһимләштерә. Һмм. Шөһрәтем Америкага кадәр барып җиткәнме икәнни? Хәер, гаҗәп түгел. Җитсә дә җитәр шул. Милләт өчен кулдан килгән кадәр эшләдек инде, Аллаһ кабул гына итсен инде. Большевиклар гына кадеремне белмәделәр.

Муса шулай сөйләнә-сөйләнә кызы Дилбәрнең дә, үзенең дә тормышы үзгәрергә мөмкин дип хыяллана башлый. Кызы профессорга ошаса, бәлки, Муса үзе дә кызы белән бергә Америкага китәр. Шушы уйлар белән ул Дилбәрне чакыра.

Дилбәр әтисенең янына чыккач, Муса аңа тиздән Америка профессоры киләчәген хәбәр итә. Муса кызын профессор алдында ничек тотарга кирәклеген өйрәтә.

— Кызым, синең бәхетең өчен тырышам. Әгәр дә чәчләрегез бәйләнгән булса, бәлки, киявебез профессор белән миңа да Америкага китәргә туры килер. Менә шуның өчен профессор алдында үзеңне яхшы тот. Теге Пётр Иванич кызыннан өйрәнгән тәртипләреңнең барысын да яса. Ул, татар булса да, Америка зыялысы инде. Күрешкәндә, ничек әле, болай итәсезме әле? Шулай посып күрешерсең, яме? Йә, эшләп кара, кара әле.

Иии, кызым, бик яхшы, күркәм чыга икән. Башыңны бераз күтәрә төш. Посканда, менә шулайрак поссаң, матуррак чыгар төсле. Күзләреңне зур итеп ачып, югарыга карап тор. Милли булсын. Ул, бердән, хөрмәт билгесе, икенчедән, килешле булып чыга. Күлмәгеңнең иң модныен ки. Хәер, өстеңдәге ярарлык икән.

Энҗе, алтыннарыңны барысын да ас, ислемаеңны кызганма. Тешләреңне яхшылап щёткалап ю. Ис килмәсен, – дип тезеп китә Муса.

Шул вакытта ишек кыңгыравы ишетелә. Озак та үтми, бүлмәгә Искәндәр белән Апуш керә. Искәндәр бу юлы Америка профессоры Булат Сон булып киенгән. Ул үзен Чикаго университетының профессоры һәм Нью-Йорк академиясе әгъзасы итеп таныштыра. Апуш аның белән йөри һәм үзен профессорның ярдәмчесе итеп таныштыра.

Муса кунакны зур хөрмәт белән каршы ала. Ул үзен элекке җәмәгать хадиме Муса Мәхмүди дип таныштыра. Искәндәр исә Мусаны һәм хәтта аның гаиләсен Америкада чагында ук ишетеп белүен әйтә.

— Муса әфәнде, мин сезне дә, гаиләгезне дә Америкада чагында ишетеп белгән идем. Муса әфәнде, мин бит сезнең әткәгезне дә беләм, әйе, әйе...

— Әй бик рәхмәт! Мин бик шат. Әйе, әйе, мәрхүм шактый мәгълүм кеше иде.

— Мин сезнең белән якыннан дуслашасым килә, Муса әфәнде! Шәһәрегездә Габдуллаҗан исемле спекулянт бар икән. Менә шул Габдуллаҗан спекулянтта Арслан ханнан калган тарихи ярлыклар бар икән. Сезнең шул хакта хәбәрегез юкмы?

— Әйе, бар, дип әйтәләр, ләкин үз күзем белән күргәнем юк. Ул аларны һичбер кемгә күрсәтми. Бик саран, ахмак бәндә.

Муса профессорга чәй тәкъдим итә. Искәндәр лимонлы чәйгә ризалаша, табынга чәй белән бергә чыжлап торган пәрәмәчләр дә килеп кунаклый. Искәндәр үзенең пәрәмәчне бик яратуын һәм Америкада егерме ел яшәгән вакытта аны авыз итмәвен әйтә. Шуңа күрә Русиягә кайткач, берьюлы егерме пәрәмәч ашарга ант иткәнен белдерә һәм Искәндәр Америка професооры кебек пәрәмәчләрне мактый-мактый, тәмләп ашый. Муса профессорны күңелле кеше дип таба.

— Сез, әфәндем, Америкада егерме елдан бирле торасызмыни?

— Әйе, егерме ел. Мин унбиш яшемдә Америкага барган идем.

— Кыяфәтегез, тфү, тфү, күз тимәсен! Бик яшь әле.

— Без, америкалылар, тиз картаймыйбыз. Гафу итегез! Әйе, гимнастика белән бик нык маташабыз.

— Менә кайнарыннан рәхим итегез. Сыйланыгыз! Профессор хәзрәтләре, сезнең ата-анагыз исәннәрме?

— Мәрхүмнәр шул.

— Әәә алааай икән, урыннары җәннәттә булсын. Нинди кәсептәге кешеләр иде?

— Әткәй, мәрхүм, инглиз флотында капитан иде. Ә әнкәй, әнкәй... Әнкәй әткәйнең хатыны иде.

— Әәә карагыз әле, профессор әфәнде, сез Американың кайсы җиреннән, шәһәреннән сәфәргә чыктыгыз?

— Пәрәмәч шәһәреннән. Ә... ни, Чикаго шәһәреннән.

— Үзегезнең ничек, рәфикагыз бармы?.. Ягъни хатынгыз бармы?

— Юк.

— Туры килмәдемени?

— Туры килмәде шул, чөнки Америкада безнең татарлардан зыялы гаиләләр юк. Ә мин үземә милли рәфика, ягъни татар кызын рәфика итәргә ант иткән идем. Үзегезгә билгеле, антны бозу – гөнаһ. Аннан соң мәрхүм әткәй белән әнкәйнең васыятьләре дә шулай иде. Хатының милли булсын, дип кычкырып үлделәр.

— Бәрәкалла, бәрәкалла. Әйбәт нәселдән икәнсез. Ә менә бездә сез эзләгән, ягъни сез теләгән милли туташлар бар. Кияүләр генә юк! Карагыз әле, профессор хәзрәтләре, минем бердәнбер кыз балам бар. Әгәр дә теләсәгез, мин аны сезнең белән таныштырыр идем. Бик тәрбияле бала инде. Шигырьләр язарга да булдыра. Аш-суга да осталыгы бар.

Искәндәр танышырга ризалаша. Муса шатланып кызы Дилбәрне чакыра. Дилбәр бүлмәгә керә һәм һәр сүзен диярлек реверанс белән озата, французча сүзләр кушып сөйләшә. Муса кызының французча белүен күрсәтергә теләп, аңардан төрле гади сүзләрне французча әйттерә.

— Без инде, профессор хәзрәтләре, азрак кызыбызга французча да укыттык. Кызым, хәерле көн французча ничек була?

— Бон жур, мусио!

— Хәерле иртә ничек була әле, кызым?

— Бон матин, мусио!

— Ә хәерле кич ничек була?

— Бон суар, мусио!

— Мин Американы яратам ничек була, йә, әйт әле?

— Жим бүлә Америк.

— Оооо! Французчаны бик һәйбәт беләсез икән. Мин Америкада чакта үз илебездә милли туташларыбыздан французча белүчеләр булыр дип һич уйламаган идем, милләтебез бик тәрәккый иткән икән, — дип әйтә Искәндәр.

— Тырыштык инде, профессор әфәнде. Кулдан килгән кадәр балаларыбызны милли рухта тәрбия итәргә тырыштык инде. Дөрес, бездә бик зур приданлы бай кызлары да бар, ләкин милли тәрбияләре бик зәгыйфь шул. Без инде кызыбызга французча да, русча да укыттык. Шуның белән бергә, милли музыка белән дә таныштырдык. Кызым, Дилбәр, профессор хәзрәтләренә берәр милли көй җырлап ал әле?

Дилбәр башта оялып торса да, аны әтисе мәҗбүр итә. Ул "Әллүки"не европача тавыш белән җырларга тырыша. Аннары "Галиябану"ны да уйный. Дилбәр бер бармагы белән көйне ялгыш-йолгыш уйнап чыкса да Искәндәр Америка профессоры кыяфәтендә моны зур уңыш итеп тасвирлый. "Яшәсен милләт!", "Яшәсен пианино!" "Яшәсен Дилбәр туташ!" дип әйтеп сала. Муса профессорның сүзләренә тагын да ныграк ышана башлый.

Шул вакытта Мусаның өенә спекулянт Габдуллаҗан килеп керә. Ул бай буларак, профессорны күрүгә иң беренче чиратта Америкадагы сәүдә һәм акча мәсьәләләре белән кызыксына башлый. Профессорның кайчан Америкадан чыкканын, анда сәүдәнең ничек баруын, акчаның алтынмы-көмешме икәнен, юлга күпме чыгым китүен – барысын да җентекләп сорый.

Искәндәр кыска җавап бирә һәм бу йорттан китәргә җыенган булып кылана башлый. Ул хәтта икенче көнне үк Америкага кайтып китәргә мөмкинлеген әйтә. Искәндәр Мусаның кунакчыллыгын мактый һәм Америкага барса, үзенә кунакка керергә тәкъдим итә.

— Рәхмәт, Муса әфәнде, милли пәрәмәчегез, лимонлы чәегез бик тәмле булды. Әгәр дә Америкага барсагыз, миңа кунак булып төшегез. Ниопост урамында торамын. 16 818 нче йортта, 84нче катта, 9987 нче номерлы фатирда, 1189 нчы бүлмәдә мин булырмын.

— Юк, юк, мин сезне, кундырмыйча, һич җибәрмим, профессор әфәнде. Минем сезгә үзегезгә генә сүзләрем, йомышларым да бар әле, — ди Муса.

Шунда Габдуллаҗан сүзгә кушылып:

— Профессор әфәндене кунарга мин үземә алып кайтам!

— Юк, бай, кеше кунагын алай тартып алып китәргә хакыгыз юк. Профессор хәзрәтләре бездә кала.

— Юк инде, Муса хәлфә, алай үзеңә генә бөтен нәрсәне йомарлап тотмыйлар аны. Профессор әфәнде иртәгә китәчәк булгач, мин аны үземә кунарга алып барам. Әйдә, профессор әфәнде.

— Әфәнделәр, әфәнделәр, тартышмагыз, мин үз номерыма кайтам – дип бәхәскә кушыла Искәндәр, әмма спекулянт Габдуллаҗан америкаи профессоры булып кыланган Искәндәрне Муса өеннән култыклап алып чыгып китә.

## Өченче күренеш

Бүген Габдуллаҗан үз өендә Америка профессеорын каршы алачак. Барысы да шуңа әзерләнә. Кунак бүлмәсендә Америка кунагы хөрмәтенә зур банкет узарга тиеш. Шуңа күрә Габдуллаҗанның хатыны **Разия** һәм аларның кызлары **Мәйсәрә** иртәдән бирле мәш килеп бүлмәне җыештыра, тузан сөртә, әзерләнә, йөгерә, ашыга.

Разия борчыла, Америкадан килгән кеше өйләренең чисталыгына карап, алар турында бөтен дөньяга фикер йөртергә мөмкин бит. Әмма Габдуллаҗанның таләпләре гади генә чисталык белән чикләнми. Ул хәзер һәр сүзгә, һәр гадәткә, хәтта хатынының үзенә ничек эндәшүенә кадәр "тәрәккый" үлчәве белән карый. Габдуллаҗан өйдәге әзерлекне тикшерә. Разия гадәттә иренә татарчалап "атасы" дип эндәшергә күнеккән, әмма татар баеның моңа ачуы кабара. Ул хатынына заманча сөйләшергә өйрәнергә куша һәм шул берничә сүзне дә үзләштерә алмауына гаҗәпләнә.

— "Атасы" дип эндәшмә әле миңа! — дип кисәтә ул. — Шул "сиңа әйтәм" белән "атасы" дигәнеңне ташла!

Габдуллаҗан өчен бу кечкенә генә гадәт түгел – ул моны искелекнең, наданлыкның билгесе дип саный. Разия кәнәфине кучерергә тотынгач та, Габдуллаҗан аның эшенә, сүзенә, хәтта ничек "бисмилла" әйтүенә кадәр бәйләнә. Ул Мәйсәрәне одеколон алып килергә җибәрә. Бүлмә һавасында ат мае исе сизелүен ул инде күтәрә алмый. Разия исә бу исне "милли ис" дип акларга тырыша.

— Милли дип инде, комганыңны да шкаф башына китереп куй! — дип каршы төшә Габдуллаҗан. — Ат мае белән милләт тәрәккый итми.

Габдуллаҗанның башында бер уй, ул Америка профессорын кызы Мәйсәрәгә өйләндерергә тели. Дөнья хәлен белеп булмый, дип уйлый ул. Америка профессоры исә үзе өчен дә, кызы өчен дә бик зур табыш. Ул профессор, мөселман, Америкада яши. Әгәр Мәйсәрә аңа кияүгә чыкса, автомобильдә генә йөриячәк, теләгән әйберен алачак, Америкада яшиячәк. Габдуллаҗан инде булачак кияүнең байлыгын саный: энҗеләр, кыйммәтле беләзекләр, теләгән нәрсәне сатып алу мөмкинлеге. Аннары Америкага күчену планы да юк түгел: яшьләр Америкадан Казанга мал җибәрәчәк, ә Габдуллаҗан белән Разия монда сатып, байлык туплап, ахыр чиктә үзләре дә Америкага китәчәкләр.

Габдуллаҗан өчен бу инде бер кызның никахы гына түгел, ә бөтен гаиләнең тормышын үзгәртәчәк зур коммерция планы.

Габдуллаҗан өенә кунаклар бер-бер артлы җыела башлый. Беренче булып Нигъмәт килә. Нигъмәттән соң Шәехмирза, Сәлим һәм башкалар килеп керә. Габдуллаҗан өенә Муса кызы Дилбәр белән дә килә. Габдуллаҗан аларны каршы алганда әйтеп куя, бу "мәҗлес" түгел, ә "зыяфәт, банкет".

Бераз көттереп булса да ишектән Америка профессоры кыяфәтендәге Искәндәр килеп керә.

Ул тыныч кына барысына да сәлам бирә:

— Әфәнделәр, сәлам!

Кунаклар бердәм рәвештә баш иеп, аны каршы алалар:

— Мәрхәбә, профессор хәзрәтләре!..

Һәм залда шунда ук тантаналы тынлык урнаша. Һәрберсе профессор алдында тәртипле, хөрмәтле һәм бик "зыялы" булып күренергә тырыша.

## Дүртенче күренеш

Шул ук бүлмәдә Мәйсәрә белән Дилбәр сөйләшеп утыралар. Өйдәгеләрнең күбесе Америкадан килгән профессор белән мәшгуль, ә кызлар үзләренең серләрен уртаклашалар.

Мәйсәрә профессорның аракы эчүенә гаҗәпләнә. Дилбәр исә укыган кешеләрнең эчәргә яратуларын әтисеннән ишеткәнен әйтә. Шулай сөйләшкәндә Мәйсәрә Дилбәргә бер серен әйтергә җыена, ләкин аны беркемгә дә сөйләмәскә ант иттерә. Аннары гына, ниһаять, серен ача: әтисе аны Америкадан килгән мөселман профессоры Булат Сонга кияүгә бирергә җыена икән.

Дилбәр моңа шикләнеп карый.

— Экскьюзми, профессор үзе ризамы соң? — дип сорый.

— Әлбәттә, әтием зур бирнә бирәчәк бит. Аның фикеренчә, акча булса, барлык эшне дә хәл итеп була.

Дилбәр исә Мәйсәрәне кисәтә: Америкага китеп, туган-тумачадан аерылып калуың бар, ди. Ләкин Мәйсәрәнең күңеле инде Америка хыяллары белән тулган. Әтисе анда большевиклар да, Советлар да юк, кешеләр автомобильләрдә генә йөри, алтын-көмеш, энҗе бик арзан, хәтта икмәк урынына шоколад ашыйлар дип сөйләгән. Шоколадның тауда үсүенә дә Мәйсәрә чын күңелдән ышана.

Шул вакытта бүлмәгә Америка профессоры, аның янында бөтерелеп йөргән кунаклар килеп керә. Берсе Америкада яшәүче татар эмигрантлары турында сораша. Искәндәр аларның исәбе-хисабы юк диярлек, хәлләре дә бик яхшы дип җавап бирә. Әмма бер үтенечләре бар икән: Русиядән арыш сохарие җибәрүләрен телиләр. Байлыклары җитәрлек булса да, туган як ризыгы сагындырган дип аңлата ул.

Аннары сүз татар тарихына күчә. Сәлим Америка галимнәренең татар тарихын өйрәнүе белән кызыксына. Искәндәр моңа җавап итеп тагын бер могҗиза уйлап чыгара.

— Профессор хәзрәтләре, татар тарихы хакында Америка голәмәсе нәрсә ди? Берәр нәрсә эшлиме?

— Бик нык эшли. Ул хакта, гомумән, эшләр бик кызу бара. Татар тарихын тикшерү өчен, махсус алтмыш биш катлы бина төзелде. Һәм дә йөз дә сигез автомобиль әзерләнде.

— Бик күп икән. Нәрсә соң ул алай Америка голәмәсен татар тарихын тикшерергә мәҗбүр итте?

— Мөһим бер ярлык. Ул ярлык хакында мондагы матбугат та бик шаулаган, дип ишеткән идем.

— Теге бер мулланың бер мужиктан урлап алган ярлыгымы әллә? – ди кунакларның берсе.

Искәндәр югалып калмыйча дәвам иттерә,

— Әйе, мужиктан бер мулла, мулладан бер хәлфә, хәлфәдән бер газета мөхбире, мөхбирдән газета конторщигы, конторщиктан китапханә мөдире, мөдирдән бер урам каравылчысы урлаган ярлык. Аны аэроплан белән бер спекулянт, Америкага китереп, миллион долларга сатты. Менә инде шул ярлык татар тарихына нык нигез ителеп алынды. Аннан соң иске Болгар ханнарының ярлыкларын, Арслан ханның бөтинамәсенең бер нөсхәсен Һинд голәмәләреннән берсе безгә, Америкага китереп тапшырды.

Сөйләшүгә Габдуллаҗан да кушыла:

— Болгар ханнарының ярлыклары, дисезме?

— Әйе, һәм Арслан ханның бөтинамәсе.

— Ул ярлыклар һәм бөтинамә ике нөсхә булганмыни?

— Әйе, ике нөсхә булган. Аны моннан сигез йөз алтмыш биш ел элек Арслан хан җыеп, ике нөсхә яздырып калдырган икән. Шуның бер нөсхәсен без таптык, икенче нөсхәсен Русиядә дигәннәр иде. Шуны эзләргә дип, мин монда килдем.

— Соң берсе булгач, аның икенчесе нигә кирәк?

— Дөрес, артык кирәге юк. Ләкин без аларны чагыштырып карамакчы булабыз. Сез, Габдуллаҗан әфәнде, шул ярлыклар хакында миңа берәр мәгълүмат бирә алмыйсызмы?

— Юк, мәгъзүр, бирә алмыйбыз. Миндә ул ярлыклар юк. Мин бернәрсә дә белмим. Аны дошманлык белән генә миндә дип әйтәләр. Миндә бер нәрсә дә юк, — дип җавап кайтара татар бае.

— Хәер, ул ярлыкларның хәзер безнең америкалылар өчен әһәмиятләре юк. Бездә бит алар бар инде. Мин болай гына сорадым.

— Ышанмыйм. Аның чыннары сездә булмас! Әйе, профессор әфәнде, ашыйсыгыз килсә, бездә аш бар, эчәсегез килсә, пирәш бар, йоклыйсыгыз килсә, түшәк бар, әмма ярлык-марлык бездә юк.

Кунаклар тарих турында сөйләшә, тарих фәне турында сораша, ә профессор шыттыра да шыттыра. Шул арада Габдуллаҗан кызы Мәйсәрәне чакыра. Ул кызын профессор белән сөйләштерергә тели. Башкалар чыгып киткәч, бүлмәдә Искәндәр белән Мәйсәрә генә кала.

Икесе бераз сүзсез утырып торалар. Искәндәр кыздан дөньядагы иң зур теләген сорый. Мәйсәрә оялып кына үз теләген әйтә:

— Минем хыялыммы? Кияүгә чыгу. Һи-һи-һи...

Искәндәр моны бик акыллы җавап дип мактый һәм аның сайлаган кияве бармы дип сорый. Мәйсәрәнең элекке кияве – энҗече Хәбибрахман улы, ә хәзерге кияве кем дип сорагач, ул бер дә икеләнмичә:

— Хәзер син минем кияү! — дип әйтеп сала.

Искәндәр үзенең кияү булып чыгуына бер дә гаҗәпләнми, киресенчә, кызның акылына соклангандай кылана. Искәндәр аны автомобильдә йөртәчәген, хәтта теләсә аэропланда очырачагын вәгъдә итә. Искәндәр үзенең йөз дә биш автомобиле барлыгын белдерә.

Мәйсәрә моңа чын күңелдән сөенә. Искәндәр биш елдан бирле аңа гашыйк булуын әйтә. Мәйсәрә исә шул вакыт эчендә ник бер сәлам хаты да язмавына аптырапса да туйны кайчан үткәрүләрен сорарга тотына.

Искәндәр исә:

— Теләсәгез, Мәйсәрә бүген үк туйларга мөмкин, — ди һәм биленә төртә.

Мәйсәрә аңа шунда ук ачуланып китә:

— Пәрәмәч!.. Нигә төртәсең? Әле никах укылганы юк ич!

Шул вакыт бүлмәгә Габдуллаҗан керә. Искәндәр аңа кызының бик акыллы булуын әйтә һәм, әгәр дә сөйләшкән сүзләре дөрес булса, аңа өйләнергә әзер икәнен белдерә.

Габдуллаҗанның шатлыгы эченә сыймый. Ул профессорның бирнә турында соравын көтә һәм күпме акча кирәк булса да бирергә әзер булуын әйтә. Әмма Искәндәр акчага мохтаҗ түгел. Аның бер генә шарты бар: бирнә итеп Болгар ханнарының тарихи ярлыкларын һәм Арслан ханның бөтинамәсен бирү.

— Миңа сез придан итеп Болгар ханнарының тарихи ярлыкларын һәм Арслан ханның бөтиен бирергә тиешсез.

— Миндә һичбер төрле ярлык юк, профессор хәзрәтләре.

— Ә мин әйтәм, бар.

— Юк, профессор әфәнде, миндә ярлык-марлык юк.

— Алай булса, гафу итегез. Мин Муса әфәнденең кызы Дилбәр туташка өйләнәм.

— Хәерче бит ул. Өстенә кияргә күлмәге дә юк бит аның.

— Мин үзем бай. Шул ярлыкларны бирсәгез,бу көннән үк мин сезнең киявегез. Берничә көннән Америкага китәрбез. Теләсәгез, сезне дә алып китәрмен. Аннан товарлар алып кайтырсыз. Миндә кирәкле язуларның барысы да бар.

— Юк, кияү, тфү… профессор әфәнде, юк миндә ярлыклар… Ничек дисез? Америкадан товар алып килеп булыр, дисезме?

— Теләсәгез, ун вагон! Сездә бит ул ярлыклар базда күмелеп яталар. Ә мине ул ярлыклар бөтен дөньяга мәшһүр итәчәкләр. Менә шулай, Габдуллаҗан әфәнде, бирсәгез, иртәгә туй. Бирмәсәгез, гафу итегез. Мин бүген үк, Дилбәр туташка өйләнеп, Америкага китәм.

— Кияү, профессор әфәнде, теләсәгез җанымны сорагыз, җәл түгел, әмма ярлыкларны бирә алмыйм. Үзем үлгәч, сезгә калдырырмын. Мирас бит ул.

— Алай булгач, гафу итегез. Ә Дилбәр туташ, рәхим итегез! Минем сезгә бик мөһим йомышым бар иде, рәхим итеп утырыгыз! — дип бүлмәгә кергән Муса кызы Дилбәрне култыклап ала.

— Дилбәр туташ, эткәгез миңа сезнең фикерегезне ирештергән иде. Мин башта Мәйсәрә туташка өйләнмәкче идем, хәзер инде сезгә өйләнергә булдым. Сез ризамы?

— Мерси, мусио!.. Әлбәттә, риза!..

Габдуллаҗан Муса белән, Дилбәр Мәйсәрә белән талаша башлый, алар бер-берсенең бугазына ябышырлык дәрәҗәгә җитә.

— Җәмәгать, сабыр!.. — дип кычкыра Искәндәр һәм Габдуллаҗанны читкә алып китә дә үзенчә сайравын дәвам иттерә. — Габдуллаҗан әфәнде, ярлыкларны бирсәгез, хәзер үк туй итәрбез. Юкса Дилбәр туташ минем хатыным дип хәзер игълан итәм.

— Әәә, профессор әфәнде, ни эшлибез соң? Уф, ярар, Аллага тапшырдым. Риза.

— Әфәнделәр, хәзер мин сезнең алдыгыз да бик зур эш ачачакмын... Әфәнделәр, мин өйләнәм... Мин Габдуллаҗан әфәнденең кызына өйләнәм!

Габдуллаҗан ярлыкларны алып керә. Ул бөтен байлыгын, бәхетен кызы белән бергә профессорга тапшыруын белдерә. Искәндәр документларны кулына алып, аларны җентекләп карый. Муса дөньяда акчага сатылмаган нәрсә юк икәненә ианып, хәтта Америка профессорлары да акчага сатылалар икән дип көрсенеп чыгып китә.

Ә Габдуллаҗан инде кияүне үз кешесе итеп күрә башлый. Мунча ягарга кушаргамы дип сорый, чәй кирәкме, ни ашарга тели - кияү алдында биеп тора бай.

Бүлмәдә Искәндәр белән Мәйсәрә генә кала. Профессор кызга ак күлмәген киеп чыгарга куша. Мәйсәрә, һаман да аның төртүеннән куркып, шаярып җавап бирә:

— Төртмә әле, юньсез, никах укылганы юк ич әле. Һи-һи-һи!..

Мәйсәрә чыгып киткәч, Искәндәр кулындагы тарихи ярлыкларга карап кала. Аннары аларны күтәреп, бүлмәдән чыгып китә. Ә Мәйсәрә күлмәкләрен киеп кире Искәндәрнең янына керсә, бүлмәдә беркем юк. Ул профессорны эзли, ләкин бүлмә буш. Тәрәзәгә карый – юк, ишекне ачып карый -– монда да юк. Ниһаять, куркыныч хәбәрне аңлый Мәйсәрсә: кияү качкан! Кияүдән җилләр искән!

— Эткәй, эткәй! Киявең качты!..

Габдуллаҗанның бу хәбәрдән соң йөрәге өзелә . Ул Мәйсәрәне гаепли "Харап булдык! Соң син, чүпрәк баш, нәрсә карап тордың?" дип ачулана. Ләкин башкалар ярсыган Габдуллаҗанны тиз генә тынычландырырга тырыша. "Тсссс, тссс! Аллам сакласын бу адәмнәр тегеннән була күрмәсен" дип пышылдыйлар. Габдуллаҗан да куркыга кала, ул тынарга мәҗбүр була .

Пьеса тәмам.

***

У нас есть и другие интересные татарские пьесы:

- **Сүнгән йолдызлар (Угасшие звезды) — Кәрим Тинчурин**
- **Беренче театр (Первый театр) — Галиәсгар Камал**
- **Банкрот — Галиәсгар Камал**
- **Әлдермештән Әлмәндәр (Старик из деревни Альдермеш) – Туфан Миңнуллин**

Если у вас есть предложения по текстам, то Вы всегда можете оставить их по адресу: **eydetat@gmail.com**

Заходите на **наш сайт**, каждый день вы найдете что-то новое и интересное! Также подписывайтесь на наши соцсети: мы есть в **Telegram-е**, **Instagram-е**, **Youtube** и **Тиктоке**.

Скоро – больше! До встречи, сау булыгыз!

This item is part of

Әйдә! Online

читаем на татарском

Азатлык Радиосы © 2026 RFE/RL, Inc. | Бар хокуклар сакланган